ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar. ru

# КАРАР

**21 август 2023 ел** **№ 26**

**«Социаль файдаланудагы торак фондының торагын арендалау шартнамәсе буенча торак алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 24 декабрендәге 39 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» РФ Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карарына ярашлы рәвештә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карарына таянып, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Башкарма комитет карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Социаль файдаланудагы торак фондының торагын арендалау шартнамәсе буенча торак алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 24 декабрендәге 39 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Формат-логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон формадагы мөрәҗәгать кыры ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры электрон формадагы мөрәҗәгатьтә мәгълүмат җиткерү аша хәбәр ителә.»;

2) 2.6.1 пунктның 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11) фамилия-исем төркеменең, туган көненең, җенесенең һәм СНИЛСның туры килүен тикшерү- Россия Федерациясенең пенсия һәм социаль иминият фонды;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ